Әлмәт шәһәре Башлыгы
карары

5 февраль 2020 ел № 03

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар уздыру турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге, «Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Әлмәт муниципаль районының Яңа Нәдер авыл җирлеге территорияләре буйлап узучы «Тозлы агымлы торбаүткәргеч» объекты өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә:

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты – 2020 елның 14 феврале 11: 00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү вакыты - әлеге карар басылып чыккан көннән алып кимендә бер айдан да ким һәм өч айдан да артык булмаган вакытка.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, шәһәр җирлеге - Әлмәт шәһәре, Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 39 й.

2.4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай проспекты, 9А йорт, 3 каб. адресы буенча урнашкан "Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе" муниципаль бюджет учреждениесенә Җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар тапшырырга.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар бирү срогы - 2020 елның 14 февраленә кадәр.

3. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) беркетмә үткәрү, әзерләү һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бирүне оештырырга.

4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов